Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктларында үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

28 нче ноябрь 2019 нчы ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми ринциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы "Иске Кыязлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының 2019 елның 5ноябрендә кабул ителгән 89 нчы номерлы "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турындагы" Карары нигезендә Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктларында 2019 нчы елның 23 ноябре һәм 28 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыеннары нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде: "2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы авылларында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны җирле әһәмияткә ия түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә куллануга ризамы:

**Торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзекләндерү:**

-Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктларындагы урамнарны төзекләндерү(балчык белән күтәртү, вак таш сатып алу һәм җәю, торбалар сатып алу);

- Иске Кыязлы авылнының Үзәк урамына ясалма тигезсезлек билгесе куйдыру;

- Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктларында юлларны кардан чистарту.

**Территорияне төзекләндерү:**

-- Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктлары өчен урам утлары сатып алу"

**"РИЗА"** **"КАРШЫ"** **"ТОТКАРЛАНУЧЫ"**

Җыен беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 962 кеше теркәлгән, җыенда катнашып, тавыш биргән кешеләр саны-465.

Җыенда катнашучыларның кул күтәреп тавыш бирүләре нәтиҗәсендә тавышлар түбәндәгечә билгеләнде:

“Риза” дип 465 кеше тавыш биргән
“Каршы” дип 0 кеше тавыш биргән
“Тоткарланучы” 0 кеше.

Алда китерелгән мәгүлуматлар нигезендә халык җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктларында үткәрелгән халык җыенын уздырылган дип, җыен нәтиҗәләрен -дөрес дип исәпләргә.
2. Җыенда күтәрелгән түбәндәге мәсьәлә буенча чыгарылган карарны кабул итәргә: “Сез 2020 нче елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы авылларында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җелган акчаларны җирле әһәмияткә ия түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә кулланугa ризамы:

**Торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзекләндерү:**

-Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктларындагы урамнарны төзекләндерү(балчык белән күтәртү, вак таш сатып алу һәм җәю, торбалар сатып алу);

- Иске Кыязлы авылнының Үзәк урамына ясалма тигезсезлек билгесе куйдыру;

- Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктларында юлларны кардан чистарту.

**Территорияне төзекләндерү:**

-- Иске Кыязлы һәм Яңа Кыязлы торак пунктлары өчен урам утлары сатып алу.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Карарны Татарстан Республикасының норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Дәүләтшин